**Татарстан Республикасы**
**Азнакай муниципаль районы**
**Татар Шуганы авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Татар Шуганы авылы №89 "01" сентябрь 2023 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы" Татар Шуганы авыл җирлеге" Советының 2014 елнын 24 гыйнварындагы 87 номерлы карары белән расланган Азнакай муниципаль районы «Татар Шуганы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында (29.11.2016 №46, 04.09.2017 №65, 03.07.2018 №104, 19.03.2019 №131, 18.02.2020 №166, 11.08.2021 №35, 24.06.2022 №63, 21.12.2022 №75, 24.07.2023 №88 карарлар редакциясендә )

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 29 декабрендәге 612-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында» Федераль законның 16 статьясындагы 2 пунктының икенче абзацының үз көчен югалтуын тану хакында, «Электр челтәре хуҗалыгы объектларының саклау зоналары чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның кайбер мәсьәләләре турында» Россия Федерациясе 2023 елның 18 февралендәге 270 номерлы карары нигезендә,

Татар Шуганы авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы"Татар Шуганы авыл җирлеге" Советының 2014 елнын 24 гыйнварындагы 87 номерлы карары белән расланган Азнакай муниципаль районы «Татар Шуганы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә ( 29.11.2016 №46, 04.09.2017 №65, 03.07.2018 №104, 19.03.2019 №131, 18.02.2020 №166, 11.08.2021 №35, 24.06.2022 №63, 21.12.2022 №75, 24.07.2023 №88 карарлар редакциясендә ) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Түбәндәге эчтәлектәге 1.7.1 пунктын тулыландырырга:

«1.7.1. 28 статьяның 7 өлешендә «башкарма документлар составы һәм аларны алып бару тәртибе,» сүзләрен төшереп калдырырга.».

1.2. 1.8 пунктындагы «в» пунктчасында «5.1.» санын «4.1.» санына алмаштырырга.

1.3. Түбәндәге эчтәлектәге 1.12 пунктын тулыландырырга:

«1.12. 36 статьяның 9 өлешендәге өченче абзацны төшереп калдырырга.».

2. Әлеге карарның 1.3 пункты 2023 елның 1 сентябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Татар Шуганы авыл җирлеге Советы торак-коммуналь хуҗалыгы, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Хәертдинов М.Ш.